# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Татарстан Республикасы халык депутатлары статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

I статья. "Татарстан Республикасы халык депутатлары статусы турында" 1990 елның 29 августындагы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы җыелма басмасы, 1992, N 1), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

"Татарстан Республикасы халык депутаты статусы турында

Татарстан Республикасы
З А К О Н Ы

Әлеге Закон Татарстан Республикасы халык депутатының хокукларын, бурычларын һәм җаваплылыгын билгеләп, депутат эшчәнлеген гамәлгә ашыруның төп хокукый һәм җәмгыяви гарантияләрен күз алдында тота.

I кисәк. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Татарстан Республикасы халык депутаты статусы турында законнар

Татарстан Республикасы халык депутаты статусы Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон һәм Татарстан Респуб-

ликасы территориясендә гамәлдә булган башка законнар тарафыннан билгеләнә.

2 статья. Татарстан Республикасы халык депутаты

Татарстан Республикасы халык депутаты Татарстан Республикасы Дәүләт Советында халыкның вәкаләтле вәкиле була, ул закон чыгару хакимиятен гамәлгә ашыра һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләр башкара. Татарстан Республикасы халык депутаты Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте вәкиле була . Үз эшчәнлегендә ул Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнарга, сайлаучыларның, республиканың һәм үзе сайланган территория берәмлегенең мәнфәгатьләренә нигезләнеп эш итә.

Татарстан Республикасы халык депутатларының барысы да бертигез вәкаләтләргә ия.

Административ-территория сайлау округыннан сайланган халык депутаты үз вәкаләтләрен, кагыйдә буларак, җитештерүдән яисә хезмәт эшчәнлегеннән аерылмыйча гына башкара, ә территория сайлау округыннан сайланган халык депутаты парламентта, кагыйдә буларак, даими рәвештә эшли.

Парламентта даими эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайланган Татарстан Республикасы халык депутатлары конституциячел баш дәүләт эш урынына караган дәүләт эш урынын алыштыра.

Хәрби хезмәткәрләр арасыннан, эчке эшләр органнарының гади һәм җитәкче составыннан, прокуратура органнары хезмәткәрләре арасыннан сайланган Татарстан Республикасы халык депутатлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан парламентта даими рәвештә эшләү өчен сайланса, алар шушы чорга элеккеге хезмәт итү урыннарындагы хезмәт итүләрен туктатып торалар.

Татарстан Республикасы халык депутатлары итеп сайланган затлар өчен хәрби хезмәт итүне, эчке эшләр органнарында һәм прокуратура органнарында хезмәт итүне туктатып тору шартлары һәм тәртибе законнар тарафыннан билгеләнә.

Депутатка үз вәкаләтләрен тоткарлыксыз һәм нәтиҗәле гамәлгә ашыру өчен шартлар тудырыла, аның хокукын, намусын һәм

абруен яклау гарантияләнә.

Татарстан Республикасы халык депутаты дәүләт хакимиятенең икедән дә артык вәкиллекле органында депутат була алмый.

Парламентта даими рәвештә эшләүче Татарстан Республикасы халык депутаты, мөгаллимлек, гыйльми яисә башка иҗади эшчәнлектән тыш, түләүле бүтән эшчәнлек белән шөгыльләнә алмый.

3 статья. Депутат эшчәнлеге гарантияләре

Халык депутатының депутат эшчәнлеге гарантияләренә түбәндәгеләр керә:

- закон чыгару инициативасы хокукы;
- законда билгеләнгән тәртиптә халык депутатының вәкаләтләрен туктату;
- халык депутатының кагылгысызлыгы;
- тикшереп тору, гарызнамә бирү, мөрәҗәгать итү, кичектергесез кабул ителү хокукы;
- дәүләт тарафыннан аңа матди һәм җәмгыяви тәэминат булдыру.

## II кисәк. Татарстан Республикасы халык депутатының Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы һәм сайлау округындагы эшчәнлеге

### 1 бүлек. Татарстан Республикасы халык депутатының вәкаләтләре чоры һәм төп хокуклары

4 статья. Татарстан Республикасы халык депутатының вәкаләтләре чоры һәм вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

Татарстан Республикасы халык депутатының вәкаләтләре чоры Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтләре чорына туры килә һәм ул биш елга тиң. Депутатның вәкаләтләре ул Татарстан Республикасы халык депутаты итеп сайланган - үзәк сайлау

комиссиясенең депутатны теркәү турындагы беркетмәсе тарафыннан расланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш халык депутатларын сайлаган көнне тәмамлана.

Халык депутатының вәкаләтләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары нигезендә түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

- депутат депутатлык вәкаләтләрен үтәүгә туры килмәслек эш урынына сайланганда яисә билгеләнгәндә;
- депутатның үз вәкаләтләрен туктатуы турындагы язма гаризасы нигезендә;
- Татарстан Республикасы гражданлыгы туктатылганда;
- Татарстан Республикасы территориясендәге хезмәт эшчәнлеген өзеп, аннан читкә даими яшәү урынына күчкәндә;
- хөкемнең гаепләү карары закон көченә кергәндә.

Татарстан Республикасы законы нигезендә үз округы сайлаучылары тарафыннан чакыртып алынган халык депутатының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

5 статья. Халык депутатының сайлаучылар белән үзара мөнәсәбәте

Татарстан Республикасы халык депутаты үз округы сайлаучылары белән элемтәдә тора, алар алдында җаваплы була һәм хисап тота. Депутат үз сайлаучыларының хокукларын, ирекләрен һәм законлы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен, аларның намусын һәм абруен яклау өчен чаралар күрә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими рәвештә эшләүче халык депутатына үз сайлау округы сайлаучылары белән эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында билгеләнгән санда һәм тәртиптә көннәр бирелә.

Сайлау округы территориясендәге җирле хакимият халык депутатына җиһазландырылган, элемтә һәм оештыру техникасы чаралары булган бина бирергә тиеш.

Сайлаучыларның ышанычын акламаган депутат законда билгеләнгән тәртиптә теләсә кайсы вакытта алар тарафыннан чакыртып алынырга мөмкин.

6 статья. Татарстан Республикасы халык депутатының төп хокуклары

Татарстан Республикасы халык депутаты үз вәкаләтләрен башкару максатларында түбәндәге хокукларга ия:

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы белән чыгарга;

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның органнары эшендә катнашырга;

- дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарында, җәмәгать берләшмәләрендә сайлаучылар мәнфәгатьләренә кагылышлы теләсә нинди мәсьәләләрне караганда катнашырга;

- депутат эшчәнлеге белән бәйле мәсьәләләр буенча барлык дәүләт һәм җәмәгать органнарына, предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга мөрәҗәгать итәргә;

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның органнары кушуы буенча, шулай ук үз инициативасы белән законнарны һәм башка хокукый-норматив актларны бозу турындагы, Дәүләт Советы карарларын үтәмәү турындагы, гражданнарның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре кысылуы турындагы белешмәләрне тикшерергә, кирәк чагында мондый тикшерүләрне үткәрү өчен предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар һәм дәүләт органнары, җәмәгать берләшмәләре вәкилләрен җәлеп итеп, комиссияләр төзү хакындагы мәсьәләне Татарстан Республикасы Дәүләт Советына чыгарырга;

- Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары эшендә киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашырга;

- депутат төркемнәре (фракцияләре), клублары, халык депутатларының берләшмәләре, үз округы сайлаучылары һәм хезмәт коллективлары җыелышлары, гражданнарның яшәү урыны буенча җыелышлары һәм хәрби хезмәткәрләрнең хәрби частьләр буенча җыелышлары эшендә катнашырга;

- Татарстан Республикасы Конституциясендә, аның башка законнарында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында, депутат эшчәнлеген җайга салучы хокукый-норматив актларда каралган башка хокукларны гамәлгә ашырырга;

- дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына, аларның урын-

дагы затларына Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә гарызнамә белән мөрәҗәгать итәргә;

- Татарстан Республикасы законнарын, аның гражданнарының хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуны кичектергесез бетерүне таләп итәргә;

- урындагы затлар тарафыннан кичектергесез кабул ителергә;

- депутат эшчәнлеген башкару өчен кирәкле мәгълүмат алырга һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре турындагы мәгълүматны өстенлекле таратырга.

## 2 бүлек. Депутатның Татарстан Республикасы Дәүләт Советындагы эшчәнлеге

### 7 статья. Халык депутатының Дәүләт Советы эшендә катнашуы

Татарстан Республикасы халык депутатлары күмәк һәм иркле фикер алышу нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында аның карамагындагы барлык мәсьәләләрне карыйлар һәм хәл итәләр.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Дәүләт Советы Регламентында билгеләнгәнчә,алдан депутатка утырышларны чакыру вакыты һәм үткәрү урыны турында, аның карамагына кертелүче мәсьәләләр хакында хәбәр итә һәм аңа әлеге мәсьәләләр буенча кирәкле барлык материалларны бирә.

Халык депутатының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның үзе сайланган органнарының утырышларында катнашуы мәҗбүри.

### 8 статья. Халык депутатының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрендәге вәкаләтләре

Татарстан Республикасы халык депутаты пленар сессиядә каралучы барлык мәсьәләләр буенча хәлиткеч тавыш хокукыннан файдалана, ә парламентта даими рәвештә эшләүче депутат шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессиясендә дә бу хокукка ия.

Сессия режимында эшләүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими рәвештә эшләми торган Татарстан Республикасы халык депутатлары да киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашырга мөмкин.

Татарстан Республикасы халык депутаты түбәндәге хокукларга ия:

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советының барлык органнарына сайларга һәм сайланырга;

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан оештырылучы органнарның шәхси составы буенча һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайланучы, билгеләнеп куелучы, расланучы яисә килештерелүче урындагы затларның кандидатуралары буенча үз фикерен белдерергә;

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына мәсьәләләр тәкъдим итәргә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләренең көн тәртибе буенча, аларны карау тәртибе һәм каралучы мәсьәләләрнең асылы буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә;

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына хисап тотучы яки аның контролендәге теләсә кайсы органның йә урындагы затның хисабын яисә мәгълүматын тыңлау хакында тәкъдим кертергә;

- Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сайлаган, билгеләп куйган урындагы затларга ышаныч белдерү-белдермәү турында мәсьәлә куягатырга;

- дәүләт һәм җәмәгать органнары, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан законнарның үтәлешен тикшерүне үткәрүнең зарурлыгы турындагы тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм аның органнарына кертергә;

- фикер алышуларда катнашырга, гарызнамәләр белән мөрәҗәгать итәргә, утырышта нотыкчыларга һәм рәислек итүчегә сораулар бирергә;

- депутат төркемнәре яисә фракцияләре төзү инициативасы белән чыгарга яки аларның эшчәнлегендә катнашырга, моның өчен сессия йә пленар сессия секретариаты аша тиешле материалларны таратырга;

- үз тәкъдимнәрен нигезләү һәм тавыш бирү мотивлары буенча чыгыш ясарга, белешмәләр бирергә;

- Дәүләт Советы утырышларының стенограммалары һәм беркетмәләре текстлары белән танышырга.

Фикер алышулар туктатылу сәбәпле чыгыш ясый алмый калган Татарстан Республикасы халык депутаты чыгышының текстын сессиянең яисә пленар сессиянең секретариатына тапшырырга хаклы, әлеге текст Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессиясенең яисә пленар сессиясенең стенографик хисабына кертелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрендә депутатлар тарафыннан кертелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр аның органнары тарафыннан закон проектларын эшләп бетергәндә йә аларны кабул иткәндә карала һәм искә алына яисә карау өчен дәүләт һәм җәмәгать органнарына, урындагы затларга җибәрелә. Аларны кире кагу очракларында депутатка дәлилле җавап бирелә.

Дәүләт Советы утырышларында депутатлар тарафыннан кертелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрелгән дәүләт һәм җәмәгать органнары, шулай ук урындагы затлар бер айдан да соңга калмыйча аларны карарга һәм нәтиҗәләр хакында Дәүләт Советы Президиумына хәбәр итәргә тиешләр.

Татарстан Республикасы халык депутатларының хокукларын гамәлгә ашыру тәртибе Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты һәм Татарстан Республикасының башка закон актлары тарафыннан билгеләнә.

Халык депутатының депутат төркемнәре, фракцияләре составындагы эшчәнлеге тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында билгеләнә.

**9 статья.** Татарстан Республикасы халык депутатының закон чыгару инициативасы хокукы

Татарстан Республикасы халык депутаты Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукына ия, бу хокук закон проектларын кертү һәм законнарга төзәтмәләр кертү рәвешендә, Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында законнар, закон проектлары әзерләү һәм кабул итү буенча закон чыгару тәкъдимнәре яисә бу законнарны көчләрен югалткан дип тану турында тәкъдимнәр кертү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

10 статья. Депутат гарызнамәсе

Татарстан Республикасы халык депутаты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына, Татарстан Республикасы Премьер-министрына, министрларга, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан оештырылучы яисә сайланучы башка органнарның (судлардан гайре) җитәкчеләренә гарызнамә белән мөрәҗәгать итәргә хаклы.

Депутат гарызнамәсе язмача яисә телдән кертелә. Язма рәвештә кертелгән гарызнамәне рәислек итүче яисә Татарстан Республикасы халык депутаты укып чыга.

Гарызнамә мөрәҗәгать ителгән дәүләт органы яисә урындагы зат Татарстан Республикасы Дәүләт Советында, өч көннән дә соңга калмыйча, телдән йә депутат таләбе буенча язмача җавап бирергә тиеш. Җавап Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессиясендә укыла. Гарызнамәгә бәйле фикер алышу нәтиҗәләре буенча карар кабул ителә.

Гарызнамә, аңа җавап һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының гарызнамәне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карары матбугатта басылып чыга.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы дәүләт органын яисә урындагы затны Дәүләт Советы билгеләгән вакытта депутат гарызнамәсе буенча кабул ителгән карарның үтәлеше турында язмача хисап бирергә мәҗбүр итә ала.

11 статья. Халык депутатының дәүләт һәм җәмәгать органнарының, җирле үзидарә органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның урындагы затларына мөрәҗәгать итүе

Татарстан Республикасы халык депутаты Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан барлык дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына, җәмәгать берләшмәләренә, җирле үзидарә органнарына, оешу-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләргә, учреждениеләргә һәм оешмаларга депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать итәргә һәм куелган

мәсьәләләрне тикшерүдә катнашырга хаклы.

Тиешле дәүләт һәм җәмәгать органнарының, җирле үзидарә органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның җитәкчеләре һәм урындагы затлары депутат эшчәнлеген башкарганда килеп чыгучы мәсьәләләрне хәл итүдә халык депутатына ярдәм итәргә, депутатны кичекмәстән кабул итәргә, аның тәкъдимнәрен карарга һәм, бер айдан да соңга калмыйча, аның нәтиҗәләре хакында депутатка хәбәр итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы халык депутаты алдан сораштыру органнарының, хөкем тикшерүчеләренең һәм судларның эшчәнлегенә тыкшына алмый.

12 статья. Депутат тикшерүе

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы хәл итүе буенча депутат тикшерүе билгеләнергә мөмкин, аны исә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан шушы очрак өчен оештырылган депутат комиссиясе үткәрә. Депутат тикшерүе үткәрү турындагы инициативаны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы органнары, кимендә биш депутаттан торган депутат төркеме белдерергә мөмкин.

Барлык дәүләт органнары һәм урындагы затлар депутат тикшерүен үткәргәндә тиешле ярдәм күрсәтергә, тикшерү алып баручы депутат комиссиясе таләбе буенча мәсьәләне объектив өйрәнү өчен кирәкле белешмәләрне, документларны тоткарлыксыз бирергә тиеш. Депутат тикшерүен алып баручы депутат комиссиясенә аңлатмалар бирүдән берәүнең дә баш тартырга хакы юк. Аңлатмалар бирүдән баш тарткан зат закон нигезендә җаваплы була. Тикшерү нәтиҗәләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм аның органнарына җиткерелә.

13 статья. Халык депутатының Татарстан Республикасы Дәүләт Советы органнарындагы эшчәнлеге

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы органнарына сайланган Татарстан Республикасы халык депутаты аларның эшендә катнашырга тиеш.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссиясе-

нә һәм башка органнары составына кермәгән Татарстан Республикасы халык депутаты аларның утырышларында катнашырга, тәкъдимнәр кертергә һәм каралучы мәсьәләләр буенча фикер алышуларда киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашырга хаклы.

Дәүләт Советы органнарының әгъзасы булган халык депутаты әлеге орган карары белән килешмәгән очракта, үзенең тәкъдимен закон проектына төзәтмә рәвешендә йә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына аерым фикер рәвешендә кертә ала.

Татарстан Республикасы халык депутаты Дәүләт Советы органы эшендә системалы рәвештә катнашмаган өчен аның составыннан чыгарылырга мөмкин. Бу хактагы карар тиешле орган тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителә.

## 3 бүлек. Татарстан Республикасы халык депутатының сайлау округындагы эшчәнлеге

### 14 статья. Халык депутатының сайлау округындагы эшчәнлегенә бәйле бурычлары

Үз сайлау округларында депутатлар:

- халыкка һәм үзләрен депутатлыкка кандидат итеп күрсәткән предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның коллективларына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның органнары эше турында, икътисадый һәм җәмгыяви үсеш программаларының, сайлаучылар мөрәҗәгатьләренең, шулай ук үзләренең сайлау алды программаларының үтәлеше турында даими рәвештә хәбәр итеп торырга тиеш;
- җәмәгатьчелек фикерен, халыкның ихтыяҗларын һәм хаҗәтләрен өйрәнергә, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле органнарына, җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр кертергә һәм аларны хәл итү өчен чаралар күрергә тиеш;
- сайлаучыларны кабул итәргә һәм округта депутат вәкаләтләрен башкару белән бәйле бүтән эшчәнлек алып барырга.

Депутат даими рәвештә, әмма ул аена бер мәртәбәдән дә ким булмаска тиеш, үз сайлау округындагы гражданнарны кабул итә. Депутат сайлаучылардан кергән тәкъдимнәрне, гаризаларны һәм шикаятьләрне карый, аларны хәл итү чараларын күрә.

15 статья. Татарстан Республикасы халык депутатының сайлаучылар алдында хисаплары

Депутат үзенең эше, сайлау алды программасының үтәлеше турында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының һәм аның үзе сайланган органнарының эше турында кимендә елга бер мәртәбә сайлаучылар каршында хисап тота.

Татарстан Республикасы халык депутатына округ сайлаучылары каршында хисаплар бирү, аларны кабул итү һәм очрашулар уздыру өчен кирәкле шартлар тудырыла. Хакимият башлыклары, җирле үзидарә органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар депутат үтенече буенча эш бинасы бирәләр, депутатның хисабын тыңлау, сайлаучылар белән очрашуларын уздыру вакыты һәм урыны турында гражданнарга хәбәр итәләр, депутат чакыруы буенча очрашуларда катнашу өчен үзләренең вәкилләрен җибәрәләр һәм башка ярдәм күрсәтәләр.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары, алар тарафыннан гамәлгә куелган массакүләм мәгълүмат чаралары, биш көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы халык депутатының хисаплары турында халыкка җиткерәләр.

Депутатның хисабы шулай ук кимендә 100 кешелек сайлаучылар төркеме таләбе буенча да уздырыла.

## Ш кисәк. Депутат эшчәнлеген гамәлгә ашыруның төп гарантияләре

## 4 бүлек. Халык депутатының хокукларын гамәлгә ашыру гарантияләре

16 статья. Закон чыгару инициативасы хокукын гамәлгә ашыру гарантияләре

Татарстан Республикасы халык депутатының закон чыгару инициативасы хокукы түбәндәге рәвешләрдә гарантияләнә:

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрендә закон чыгару инициативасы тәртибендә кертелгән тәкъдимне катгый рәвештә карау һәм түбәндәге карарларның берәрсен кабул итү:

закон кабул итү; яңа закон проекты әзерли башлау турында карар кабул итү; тәкъдим ителгән закон проектын эшләп бетерү өчен тиешле даими комиссияләргә җибәрү; тәкъдим ителгән закон проектын дәлилләп кире кагу;

- Татарстан Республикасы халык депутаты тарафыннан законга кертелгән тәкъдимнәрне, шулай ук барлык төзәтмәләрне катгый рәвештә тавышка кую.

17 статья. Татарстан Республикасы халык депутатының урындагы затлар тарафыннан кичектергесез кабул ителү хокукы

Татарстан Республикасы халык депутаты Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан барлык дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының, җәмәгать берләшмәләренең, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның урындагы затлары тарафыннан депутат эшчәнлеге буенча кичектергесез кабул ителүгә хаклы, шулай ук аларның һәрберсенә тоткарлыксыз керү хокукына ия. Оборона, эчке эшләр министрлыкларының учреждениеләренә, оешмаларына һәм режимдагы бүтән предприятиеләргә керү законнарда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

18 статья. Татарстан Республикасы халык депутатының мәгълүмат алу һәм тарату хокукы

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы халык депутатын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы документлары белән, шулай ук аның үтенече буенча хөкүмәт һәм дәүләтнең башка органнары, җәмәгать органнары тарафыннан рәсми рәвештә таратылучы мәгълүмати һәм белешмә материаллардан файдалана алуын да тәэмин итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы халык депутаты мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләтнең башка органнары һәм җәмәгать органнары, шулай ук урындагы затлар аны депутат эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча белгечләрнең киңәшләре белән тәэмин итәргә, аңа кирәкле мәгълүматларны кичекмәстән бирергә тиешләр.

Татарстан Республикасы халык депутатына дәүләт сере бул-

ган мәгълүматларны һәм документларны бирү законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Депутат эшчәнлеген башкару өчен кирәкле мәгълүматлар, документлар һәм аларның күчермәләре депутатка бушлай бирелә, шуңа бәйле чыгымнар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы исәбеннән түләнә.

Татарстан Республикасы халык депутаты дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган массакүләм мәгълүмат чараларында депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча чыгыш ясау өчен өстенлекле хокукка ия. Депутат тәкъдим иткән материаллар аның ризалыгыннан башка редакцияләнмәскә тиеш.

<u>19 статья.</u> Татарстан Республикасы халык депутатының намусын һәм абруен яклау

Татарстан Республикасы халык депутаты, дәүләт хакимияте вәкиле буларак, дәүләтнең махсус яклавында була. Аның гаилә әгъзалары, шулай ук мөлкәте дә дәүләт яклавына ия. Халык депутатыннан тиешле гариза кергән очракта, хокук саклау органнары халык депутатының, аның гаилә әгъзаларының иминлеген, аның мөлкәтенең сакланышын тәэмин итәрлек чаралар күрергә тиеш. Депутатның намусына һәм абруена кагылучы затлар законнар нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

<u>20 статья.</u> Депутат эшчәнлегенә комачаулык итүче урындагы затларның җаваплылыгы

Дәүләт һәм җәмәгать органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның депутат алдында үз вазыйфаларын үтәмәүче, аның эшенә комачаулаучы, күрәләтә аңа ялган мәгълүмат бирүче, депутат эшчәнлеге гарантияләрен бозучы урындагы затлары законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартылалар.

<u>21 статья.</u> Татарстан Республикасы халык депутатының закон бозуны төзәтүне таләп итү хокукы

Гражданнарның хокуклары, ирекләре, законлы мәнфәгатьләре бозылу һәм законнар бозылу очраклары ачылганда, депутат мондый

хокук бозуларны кичекмэстэн тэээтүне талэп итэргэ яисэ, ачыкланган хокук бозуларны кичекмэстэн бетерүне талэп итеп, тиешле органнарга һәм урындагы затларга мөрәҗәгать итәргә хаклы.

Депутатның законлы таләпләрен үтәмәүдә гаепле зат закон нигезендә җаваплылыкка тартыла.

### 5 бүлек. Татарстан Республикасы халык депутатының кагылгысызлыгы һәм депутатны җаваплылыкка тарту тәртибе

**22 статья.** Татарстан Республикасы халык депутатының кагылгысызлыгы

Татарстан Республикасы халык депутаты барлык вәкаләтләре чорына кагылгысызлыкка ия. Татарстан Республикасы территориясендә депутат хөкем итү тәртибендә билгеләнә торган җинаять җаваплылыгына яисә административ җаваплылыкка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы ризалыгыннан башка тартылмый, тоткарланмый, кулга алынмый, аңа тентү ясалмый.

Татарстан Республикасы халык депутатына карата җинаять эше бары тик Татарстан Республикасы Прокуроры тарафыннан гына кузгатылырга мөмкин.

Депутатның торагы һәм хезмәт итү урыны, аның шәхси әйберләре һәм багажы, файдалана торган транспорты һәм элемтә чаралары, хатлары, шулай ук документлары кагылгысыз була.

Әлеге статьяның нигезләмәләрен бозган өчен закон нигезендә җаваплылык билгеләнә.

**23 статья.** Татарстан Республикасы халык депутатын җаваплылыкка тарту өчен ризалык алу тәртибе

Татарстан Республикасы халык депутатын җинаять җаваплылыгына тарту яисә аңа карата хөкем тәртибендә билгеләнә торган административ чаралар куллану, аны тоткарлау, кулга алу, тентү ясау буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы ризалыгын алу өчен Татарстан Республикасы Прокуроры депутатны гаепләр алдыннан, административ хокук бозу турындагы эшне судка җибәрер алдыннан, тоткарлауга, кулга алуга, тентү ясарга санкция бирер

алдыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим кертә.

Татарстан Республикасы Прокуроры тәкъдиме бер айдан да соңга калмыйча карала.

Кирәк булганда Татарстан Республикасы Прокурорыннан өстәмә материаллар соратып алынырга мөмкин. Үзенә карата тәкъдим кергән Татарстан Республикасы халык депутаты мәсьәләләрне карaганда катнашырга хаклы. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы дәлилләнгән карар кабул итә һәм бу хакта өч көн эчендә Татарстан Республикасы Прокурорына хәбәр итә.

Татарстан Республикасы Прокуроры эш каралып беткәннән соң өч көн эчендә эшне тикшерү яисә карау нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына хәбәр итәргә тиеш.

### 6 бүлек. Татарстан Республикасы халык депутатының хезмәт хокуклары гарантияләре һәм аның эшчәнлеген матди-көнкүреш яктан тәэмин итү

**24 статья.** Татарстан Республикасы халык депутатының хезмәт хокуклары гарантияләре

Татарстан Республикасы халык депутаты Татарстан Республикасы Дәүләт Советы ризалыгыннан башка хакимият инициативасы буенча предприятиедә, учреждениедә яисә оешмада эшеннән азат ителми, уку йортыннан җибәрелми яисә дисциплинар җәзага тартылмый.

Хәрби хезмәткәрләр һәм хезмәт итүләре уставлар һәм нигезләмәләр белән регламентлаштырыла торган башка категория гражданнар арасыннан сайланган Татарстан Республикасы халык депутаты хакимият яки командование инициативасы буенча хезмәт итүдән азат ителми, түбәнрәк эш урынына күчерелми, аның званиесе түбәнәйтелми, шулай ук ул үз ризалыгыннан башка бүтән эшкә күчерелми. Аңа үзе биләгән хезмәт урынына туры килә торган чираттагы офицер званиесе яки офицер званиесенә тиң махсус звание бирү тоткарланмый.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими эшләүче Татарстан Республикасы халык депутатына депутат вәкаләтләре тәмамланганнан соң элеккеге эше (хезмәте) тәкъдим ителә, ә ул сакланмаганда - шул эш урынында яисә аның ризалыгы белән бүтән

предприятиедә, учреждениедә, оешмада элеккегесенә тиң үзгә эш (хезмәт) тәкъдим ителә.

Хәрби хезмәткәрләр һәм эшчәнлекләре уставлар һәм нигезләмәләр белән регламентлаштырыла торган эчке эшләр органнары хезмәткәрләре, прокуратура органнары һәм башка органнар хезмәткәрләре арасыннан парламентта даими рәвештә эшләү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайланган Татарстан Республикасы халык депутатына депутат вәкаләтләре тәмамланганнан соң гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә элеккеге эш урыны бирелә, ә ул сакланмаганда - шул ук хезмәт урынында яисә аның ризалыгы белән башка хезмәт урынында элеккегесенә тиң бүтән эш яки югарырак эш урыны тәкъдим ителә.

Халык депутатының Татарстан Республикасы Дәүләт Советында һәм аның органнарында даими рәвештә эшләгән вакыты гомуми һәм өзлексез эш (хезмәт) стажына, белгечлеге буенча эш (хезмәт) стажына кертеп санала, тиешле еллар хезмәт иткән өчен (әлеге предприятиедә белгечлеге буенча эш (хезмәт) стажы өчен) хезмәт хакына өстәмәләрнең һәм ташламаларның барлык төрләрен, процентлы өстәмәләр билгеләү хокукы бирүче һәм бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү хокукы бирүче, тиешле еллар хезмәт иткән өчен процентлы өстәмә алу хокукы бирүче эш (хезмәт) стажына кертеп, шулай ук ташламалы шартларда һәм ташламалы күләмнәрдә пенсия алу (депутат булып сайланганчы, аның эше һәм һөнәре буенча әлеге ташлама күздә тотылган булса) хокукы бирүче эш (хезмәт) стажына кертеп санала.

<u>25 статья.</u> Татарстан Республикасы халык депутатын җитештерү яисә хезмәт вазыйфаларыннан азат итү тәртибе

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан парламентта даими эшләү өчен сайланган Татарстан Республикасы халык депутаты бер ай эчендә яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы билгеләгән башка вакыт дәвамында элеккеге эш урыныннан китәргә яки законнарда каралган очракларда үз хезмәтен (вәкаләтләрен) туктатып торырга тиеш.

Җитештерү яисә хезмәт эшчәнлегеннән аерылмыйча үз вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы халык депутаты депу-

тат эшчәнлеген гамәлгә ашыру чорына төп эш (хезмәт) урынындагы хакимиятне язмача искәртүе нигезендә җитештерү яисә хезмәт вазыйфаларыннан азат ителә.

<u>26 статья.</u> Татарстан Республикасы халык депутатының транспортта бушлай йөрү хокукы

Татарстан Республикасы халык депутаты Татарстан Республикасы территориясендәге барлык тимер юл, һава юлы, автомобиль, эчке су юллары транспортыннан һәм, таксидан гайре, шәһәр пассажир транспортының барлык төрләреннән бушлай файдаланырга, шулай ук юлда йөрү документларын чиратсыз алырга хаклы.

Бу хокук беренче төркем инвалид депутатны җитәкләп йөрүче затка да кагыла.

<u>27 статья.</u> Татарстан Республикасы халык депутатының элемтә чараларыннан файдалануы

Татарстан Республикасы халык депутаты үзенең депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы акчалары исәбенә Татарстан Республикасы территориясендәге дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның барлык төр элемтә чараларыннан файдаланырга хаклы. Халык депутатының элемтә хезмәтеннән чиратсыз файдаланырга хакы бар.

<u>28 статья.</u> Татарстан Республикасы халык депутатына үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен матди-көнкүреш шартлар тәэмин итү

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими рәвештә эшләүче халык депутатына:

- Татарстан Республикасы Дәүләт Советы бинасында җиһазлары, оештыру техникасы, элемтә чаралары булган аерым эш бүлмәсе бирелә;

- Татарстан Республикасы министрының хезмәт хакы һәм шушы хезмәт хакына өстәмәләр күләмендәге хезмәт хакыннан һәм шуңа өстәмәләрдән торучы акчалата айлык түләү билгеләнә;

281



- әгәр депутатның Казан шәһәрендә даими яшәү урыны булмаса, аның гаризасы нигезендә ике ай эчендә хезмәт урыны буенча вакытлыча яшәү өчен торак урыны бирелә, шулай ук Казанга күчеп килү чыгымнары һәм,аның даими рәвештәге эшчәнлеге тәмамлангач, аңа һәм аның гаилә әгъзаларына яңадан әйләнеп кайту чыгымнары компенсацияләнә;

- депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыру чорына аларның төп яшәү урыннарындагы торак мәйданы аларга беркетелә;

- ял итү өчен кирәкле шартлар тудырыла, шул исәптән һәр ел саен 36 эш көне дәвамында түләүле отпуск бирелә, шул ук вакытта икеләтелгән айлык акчалата түләү күләмендә дәвалану өчен пособие бирелә;

- аңа һәм шул исәптән аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларына медицина хезмәте күрсәтелә;

- депутат эшчәнлеген гамәлгә ашырганда шәхси транспортыннан файдаланган өчен компенсация түләнә.

Житештерү яисә хезмәт эшчәнлегеннән аерылмыйча үз вәкаләтләрен башкаручы халык депутатына, ел саен бирелә торган отпускысын 36 эш көненә кадәр җиткереп, түләүле өстәмә көннәр бирелә, үзенә һәм шул исәптән аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларына медицина хезмәте күрсәтелә, депутат эшчәнлеген башкарганда шәхси транспортыннан файдаланган өчен компенсация түләнә.

Татарстан Республикасы халык депутатының тормышы һәм сәламәтлеге Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары хисабыннан дәүләт тарафыннан иминләштерелә, бу сумма Татарстан Республикасы Дәүләт Советында даими эшләүче депутатның еллык акчалата хезмәт хакына тиң була. Депутатның тормышына һәм сәламәтлегенә депутат эшчәнлеген башкару аркасында зыян китерелсә, иминләштерү суммасы түләнә.

Татарстан Республикасы халык депутатларына депутат эшчәнлеген гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнар Татарстан Республикасында билгеләнгән бер минималь хезмәт хакы күләмендә ай саен кире кайтарыла, аңа салым салынмый.

Татарстан Республикасы халык депутатының ике генә ярдәмчесе була.

Татарстан Республикасы халык депутаты ярдәмчесенә билгеләнгән үрнәктәге таныклык бирелә.

Дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның халык депутатының эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча гарантияләрне һәм шартларны матди тәэмин итү белән бәйле барлык чыгымнары Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән түләнә, бу чыгымнар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чыгымнары сметасына кертелә.

Әлеге статьяның нигезләмәләрен гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раслый торган Нигезләмә тарафыннан җайга салына.

29 статья. Татарстан Республикасы халык депутатының депутат таныклыгы һәм күкрәк тамгасы

Депутат үз вәкаләтләре чорында депутат таныклыгыннан һәм күкрәк тамгасыннан файдалана.

Татарстан Республикасы халык депутаты таныклыгы һәм аның күкрәк тамгасы турындагы нигезләмә, аларның үрнәкләре һәм тасвирламасы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана".

2 статья. Әлеге Закон басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә. 22 статьяның 1 өлешендәге һәм 23 статьяның 1 өлешендәге тоткарлау һәм тентү ясау турындагы нигезләмәләр Татарстан Республикасы Конституциясенә тиешле үзгәрешләр керткәннән соң гамәлгә кертелә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 30 мае
N 611